**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№311**
**26.01.2022**

Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары белән расланган эш урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2010 елның 23 мартындагы 1808 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 18 октябрендәге 5458 номерлы, 2020 елның 16 мартындагы 1222 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган эш урыныннан бирелә торган торак урыннарны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан, гражданнарга эш урыныннан торак урыннар биргән оешмаларда эш урыныннан бирелүче торак урыннар алганнан соң тулы ун ел дәвамында эшләгән затларның гаризалары буенча;»;

- 5 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

2) 4 пунктта:

- җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы дәүләт теркәү органыннан гариза бирүче гаиләсенең хокукка сәләтле һәр әгъзасы тарафыннан бирелә торган гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу яки булмау турында мәгълүматлар;»;

- түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) җитәкчесенең үтенеч язуы, эшләү чорында эш урыныннан торак урын бирелгән

дәүләт органы (җирле үзидарә органы), предприятие (учреждение) белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торуын дәвам итүче затлар өчен.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов